**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ТҮБӘН СУЫКСУ» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

« 23 »январь 2023 ел Түбән Суыксу авылы № 1/2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегендә гражданнарны сораштыруны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, Түбән Суыксу авыл җирлеге Уставы нигезендә Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегендә гражданнарны сораштыруны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» муниципаль берәмлек Советының 2008 елның 23 маендагы 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегендә гражданнарны сораштыруны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 22 статьяның 1 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«яки Түбән Суыксу авыл җирлеге халкын»;

1.2. 8 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гражданнарны сораштыруны билгеләү турында карар Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнарны сораштыру үткәрү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайты файдаланылырга мөмкин.

Гражданнарны сораштыру буенча карарда билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм вакыты;

2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауның (сорауларның) формулировкасы;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5) сораштыруда катнашучы муниципаль берәмлектә яшәүчеләрнең минималь саны;

6) интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтын кулланып сораштыру үткәргән очракта, катнашучыларны тәңгәлләштерү тәртибе.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Суыксу авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

ТР Тукай муниципаль районы
Түбән Суыксу авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г. Ихсанов